*Инсафутдинова М. Т. (РИИ, Казань)*

# СОВРЕМЕННЫЙ ЯЗЫКОВОЙ ПРОЦЕСС В РОССИЙСКОМ ИСЛАМСКОМ ИНСТИТУТЕ

**Аннотация:** В данной статье рассмотрены проблемы преподавания современного татарского языка, языковой процесс в рамках Российского исламского института. Проанализирован процесс обучения студентов татарскому языку. Выявлена и обоснована необходимость коммуникативных технологий в обучении. Автором предлагается активно использовать этно-культурные компоненты, формулируются основные характеристики лингвистического обучения в институте.

**Ключевые слова:** современный татарский язык, билингвизм, лингвокультура, лингвистические компетенции, преподавание татарского языка, национально-культурный компонент, коммуникативная компетенция, культура речи

**Modern linguistic processes in the Russian Islamic Institute**

**Summary:** This article discusses the problems of teaching modern Tatar language, linguistic process within the Russian Islamic Institute. Examined the process of teaching students the Tatar language. Spotted and the necessity of ICT in education. The author proposes to actively use the ethno-cultural components, with the main characteristics of the linguistic training at the institute.

**Keywords:** modern Tatar language, bilingualism, linguistic

culture, linguistic competence, the teaching of the Tatar language, national and cultural component, communicative competence of speech

Будда 150 телдә аралашкан, ә Мөхәммәд пәгамбәр (с.г.с.) дөньядагы барлык телләрне дә белгән.

Бүгенге көн җәмгыятебездә кешенең сөйләм теленә аеруча югары таләпләр куела. Эш яки уку урыннарында бернинди киртәсез аралаша алу сәләте, җәмгыяти яшәешнең һәрдаим үзгәреп торган шартларда җиңел адаптацияләшә алу, мәгълүматлар зур тизлек белән үзгәргән чорда тагын да җитез булу – бүгенге көн уңышлы специалистның мөһим сыйфатларының берсе. Телләр өйрәнүдә эффектив юллар эзләү лингвокультурологик ысулга алып килде. Аның нигезендә телне өйрәнү белән бергә, шул телнең мәдәниятен өйрәнү дә күздә тотыла. Ягъни студентларда лингвистик, филологик компетенцияләргә генә түгел, коммуникатив, социокультур аспектларга да басым ясала. Лингвокультурология тел берәмлекләренең милли семантикасын тулы яссылыкта өйрәнә. Социокультур компетенция тормыш-көнкүрештә очраган ситуацияләрдә аралашу гына түгел, шул халыкның мәдәнияте, әдәбияты һәм башка сәнгать төрләре белән таныша алу мөмкинлеген бирә.

Татарстан республикасында икетеллелек – тел үсешенең төп тенденцияләренең берсе. Безнең күпмилләтле республикабызда бу аеруча мөһим. Татар-рус икетеллелеге генә түгел, башка милләтләрнең телләре дә лингвокультурологиягә зур йогынты ясый.

Республикабызда тел сәясәтенең тормышка ашыруның этәргече - татар телен югары белем бирү системасына кертү булды. Россия ислам институтының “Филология һәм илләр өйрәнү” факультеты 2007нче елда барлыкка килде, ләкин татар телен укыту моңа кадәр дә алып барылды. Бередә татар телен өйрәтүдә актив рәвештә методик эш алып барыла. Студентлар белән фәнни һәм иҗади эшчәнлек алып бару өчен барлык шартлар тудырылган. Татар телен укыту милли үзаңны формалаштыруга юнәлдерелгән.

Актив икетеллелек билингвизмга нигезләнә. Рус теле татар теленә ничек тәэсир ясаса, татар теле дә рус теленең үсешенә, торышына зур йогынты ясый. Студентлар белән тыгыз эш алып барганда, рус теленең татар сөйләменә аеруча нык кагылуы сизелә. Актив икетеллелек шартларында тере татар сөйләме гаять гадиләшә. Шуңа күрә, төрле сүзтезмәләр составына

рус сүзләре килеп керерә. Бу күренеш татар теленә тискәре яктан йогынты ясамаса да, шулай да сөйләм культурасы берникадәр түбәнәя дип әйтергә кирәк. Әлеге күренеш киләчәк имамнар, журналистлар һәм башка төр һөнәр ияләренең телен кимсетә, әлбәттә.

Институтыбызны тәмамлаган дипломлы белгечләребезнең сөйләм культурасын югары итү – төп макстатыбызның берсе. Моны без телне уртача белгән студентта булдыра алабыз. Гарәп телен өйрәнү белән бергә, рус теленнән килеп кергән алынмалар инде берникадәр онытылган гарәп-фарсы алынмалары белән алмаштырылып, уңышлы гына актив файдаланыла башлады: "договор" урынына "шартнамә", "союз" – "ширкәт", "политика" – "сәясәт", "куратор" – "остаз", "экономика" – "икътисад" , "стена" – "дивар", "рубрика" – "сәхифә", "расписание – "җәдвәл" һ.б.

Шул ук вакытта Россия ислам институтында татар телен укыту процессында язма телне камилләштерү өлкәсенә дә зур игътибар бирә. Чөнки хәзерге татар әдәби теленең грамматик нормаларын үзләштермичә, аның кагыйдәләренә игътибар бирмичә, ягъни мәсәлән, сүз басымы, дөрес әйтелеш һәм язылыш дисеңме, стилистик яклары дисеңме һ.б. өлкәләрен өйрәнмичә генә, сөйләм культурасын тиешле дәрәҗәдә үстереп булмаячак. Шуңа күрә дә "Филология һәм телләр өйрәнү кафедра"сының укытучылары тарафаннан яңа федераль белем бирү стандартларына нигезләнеп эш программалары, укыту-методик комплекслар төзелде һәм нәшер ителде. Биредә мәктәпләрдә калдырылган ак таплар исәпкә алынды, этнокультуралы компонент та читләтеп үтмәде. Алай гына да түгел, "Иске татар теле" дип аталган курс та уңышлы гына укытылып килә. Әлеге фәнне студентлар аеруча зур кызыксыну белән укыйлар, чөнки татар телен өйрәнү белән бергә, аның тарихын, генезисын, килеп чыгышын белү дә мөһим һәм игътибарга лаек. Шушы дәресләрдә алар иске татар телендә язылган мирас итеп калган китаплар укырга өйрәнәләр. Бу уңайдан студентларның XVII - XIX йөз кулъязма истәлекләре белән танышу мөмкинлеге дә туа. Һичшиксез, институтыбызда белем алучылар дини эчтәлекле татар әсәрләрен тагы да зур ихтирам белән өйрәнәләр. Ә инде 3 курс шәкертләре "Дини текстлар уку" курсын бер семестр буе дәвам итәләр. Әлбәттә, мондый курсларның укытылуы хәзерге татар әдәби телен өйрәнүгә тагы да зур этәргеч бирә.

Хәзерге татар әдәби теле дәресләрендә исә, студентлар күбрәк мини-этюдла төзергә, телдән иҗади миниатюралар төзергә, диалоглар белән эш тәргә яраталар. Бу очракта студентлар җитмәгән лексик берәмлекләрне үзлектән табып файдалананалар мәҗбүр булалар. Ә укытучы бары тик юнәлеш биреп торучы куратор ролен генә үти. Семетр дәвамында һәр студент бер генә булса да иҗади эш башкара: иншалар бәйгесе, юбиляр шәхесләребезгә багышланган рефератлар башкару яки шигырь язу, сәнгатьле сөйләү осталыгында ярышлар уздырыла. Институт күләмендә оештырылган “Милли атналык”ларда да актив катнашалар. Мондый чаралар студенларга менталитетыбызның үзенчәлегенә төшенергә мөмкинлек бирә, милли мәдәниятебезнең дөньяви культурысында тоткан урынын билгели.

“Син никадәр тел белсәң – шуның кадәр син кеше” (А.П.Чехов).

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1. Асадуллин А.Ш. Из опыта преподавания русского языка в татарской школе / А.Ш.Асадуллин – Казань, 1981. – 246 с.

2. Гафиатуллина Э.Х. Рус телле балаларга татар телен укытуда туган проблемалар // Актуальные проблемы обучения татарскому языку в русской школе: Материалы II республиканской научно-практической конференции. – Казань, 2005. – С.97-104.

3. Лотте Д.С. Вопросы заимствования и упорядочивания иноязычных терминов и терминоэлементов / Д.С.Лотте – М.: Наука, 1982. – С.149.

4. Хайруллин М.Б. Глобализация и развитие национальных культур и языков / М.Б. Хайруллин – Казань: АКФ, 1996. - 482 с.